# **Үткәннәргә сәяхәт.**

Сценарийның авторы: Гыйндуллина Гөлфинә Нуррахман кызы.

Максат һәм бурычлар:
1. Татар халкының элекеге көнкүреше белән таныштыру, гореф – гадәтләрен хәтердә яңарту һәм саклау, элекке чорның матурлыгын күрсәтү;
2. Балаларда татар халкының җырлы – биюле уеннарына, авыз иҗатына мәхәббәт уяту;
3. Сәнгатьле сөйләм телен үстерү.
4. Үз халкыңа карата ихтирам, горурлык хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: Милли итеп бизәлгән татар йорты. Мич,сәке,бишек,сандык, һәм дә элекеге көнкүрештә кулланыштагы әйберләр.

Балалар милли киемдә.

Музыка.

**Алып баручы:** Үткәнен онытмаган халык кына бөек, һәм ул мәңгелек. Җир йөзеннән халык кадәр халык югала икән, бу бик куркыныч, аяныч хәл. Әйдәгез, узебезне шушындый олы гөнаһлардан саклыйк, ата-бабаларыбызның серле дә, изге һәм дә тылсымлы дөньяларына сәфәр тотыйк, борынгы татар ызбасында булып кайтыйк.

**Әби** :Кызым,күрше әбиең чакырган иде. Кереп чыгыйм әле. Хәлен дә белермен,әзерәк янында утырып та чыгармын.

**Эльвина :**Бик якшы, әбекәй. Бүген минем кырыма да, кызлар киләбез дигәннәр иде.

**Әби:** Ярый,ярый,тик акыллы булыгыз,тәртип булсын.

**Эльвина:** Ярар,әбекәй ,борчылма.

**Әби:** Ярый, мин сиңа ышынам, кызым.

**Китә. Кызлар керә.**

**1Кыз:** Исәнме,Эльвина.

**Бергә:** Сәлам,сәлам!

**Эльвина.** Әйдәгез,узыгыз,кызлар.

**Лиана**: Кызлар, карагыз ничек матур монда ,ә безнен өйдә бөтенләй башкача.

**Эльвина:** Минем əти-əниләр дә хәзер заманча яшиләр.Ә менә әбекәйдә, барысы да борынгыча. (сондыкны  күреп ала)

**Эльнара:** Кызлар, карагыз әле нинди матур ,зур чемодан.

**Эльвина:** Бу чемодан түгел,сондык.Ә беләсезме,кызлар, әбиемнең 3 сондыгы булган.Ул аларны берсе өстенә берсен тезеп куя торган булган.

**Алина,Ильнара:** Ә нигә ул кәдәр сондык?

**Кызлар:** Әйе.

**Эльвина:** Ул сондыкларда, өч кызына бирнә әзерләгән.Кызлары үзләре дә кич утырып сөлге ,алъяпкыч,ашъяулыклар чиккәнәр. Шул сондыкларда саклаганнар. Ә кияүгә киткәндә үзләрен , сондык тулы ,бирнә белән озатканнар. (сондыкка күрсәтеп) Монысы, әбекәйнен  узенең  сондыгы. Ул анда балаларына, оныкларына,истәлеккә калдырасы, иң кадерле әйберләрне саклый.

**1 Кыз:** Ә менә бу - бәләкәй сондык нигә?

**Эльвина:** Ә ул бик тәмле сондык.Анда әбекәем прәниген, кәнфитен ,чәк-чәкләрен  салып куя.

**Балаларның күзләре, эленеп торган бәллүгә  төшә.**

**Рината:** Ә нигә әбигә бәллү кирәк?

**Эльвин :** Бәләкәй оныкларына.Алар кунакка еш киләләр.

**Кызлар:** Ә-ә-ә

**Эльвина:** Әлегә анда минем курчагым йоклый.

**Алина:** Ә курчагыңа бишек җырын җырлыйсыңмы соң?

**Эльвина:** Җырлыйм.

**Ильнара:** Мин дә курчагымны җырлап йоклатам.

**Бәллү тирбәтә.**

Әлли бәлли бәбкәсе

Кая киткән әнкәсе

Каенлыкка җиләккә

Бәбкәсенә бүләккә.

**Әби керә.**

**Әби:** И-и-и, балайкайларым, бөтенләй онытканмын.  М ичкә бәлеш  тыккан идем  бит.

**Рината:** Тәмле исләр чыккан иде шул.

**Әби:** Хәзер монауы чүлмәкне алып куям да...(чүлмәкне мичтән алып куя )Бу чүлмәктә җылы су, балам,савыт-саба юарга, юынырга булыр дидем.

**Зилэ:** Карагыз әле, нинди мөгез сөяп куйганнар дисәм, менэ ул нәрсә өчен икән.(ухватны алып тотып карый).

**Әби:** Әйе,балалар, ул ухват дип атала,менә шулай чуен чүлмәкләрне шап итеп эләктереп ала.

**Кулына табагач ала.**

Ә менә монысы- табагач.Хәзер бәлеш белән табаны эләктереп ала да,чыгарып куя.

**Бәлешне чыгарып куя.**

**Лиан :** Үрдәк авызына охшап тора.

**Әби**: И,балалар,хәзер  көнкүрештә болар берсе дә кулланылмый шул.Белмәсәгез дә гаеп түгел.Ә белү кирәк  эш,балалар.

**Кулына кисәүгач ала.**

Менә монысы кисәүгач,күмерне мичтән тартып ала.Монысы кыскыч, күмерне самауыргa сала. И-и-и, самаурымны яңартып, көйрәтеп   җибәрим әле.Рәхәтләнеп бәлеш ашап ,чәй эчәрбез.

**Самаурга күмер сала ,читек белән өрдерә.  Шушы урында читекнең нинди роль уйнавы турында сөйли.**

**Әби**:  Кызым ,мин кече якка чыгып, кул  эшем белән  утырам. Сез рәхәтләнеп сөйләшегез, серләшегез.

**Эльвина:** Ярый ,әбекәй.

**Кызлар:** Рәхмәт.

**Әби чыга.**

**Виолетта:(**сәкегә барып утыра) Кызлар, мин җөн эрләп алыйм әле.

**Көнҗәлә кырына утырып, җөн (йон) эрләгән булып кылана.**

**Эльнара:** Әллә, эрли беләсеңме?

**Виолетта:** Юк, шаяртам гына.

**Рината:** Ә мондый җөнле таяк, минем әбекәйнеке дә бар .

**Эльвина:** Җөнле таяк түгел.Ул көнҗәлә дип атала.

**Кызлар:** Көнҗәлә??????

**Виолетта:** Беренче тапкыр ишетәм .

**Кызлар** :Без дә.

**Эльнара :** Кызлар, җ өн сөйләгәч исемә төште.Без дә бит кул эшләрен алып килгән идек.

**Кул эшләрен алып утыралар.**

**Эльвина:** Мин тугандагы тынлык.Сөйләшергә сүз беттеме әллә ? Ягез, алайса җырлашып алыйк.

**Эльнара :** Кызлыр, сез таң атканда, кошлар сайравын тыңларга яратасызмы?

**Алина:** И-и-и ,Эльнара ,кем соң яратмый кошлар сайравын.

**Бергә:** Әйе.

**Виолетта:** Әйе, син дә сорап торасың.

**Эльнара:** Ягез әле, алай булгач, кошлар турында җырларны кем күберәк белә икән, җырлашып ярышабыз.

**Эльвина:** Әйдәгез, ике якка бүленеп җырлыйбыз.

**Җыр ярышы. Икенче як кошлар турында җыр таба алмагач,**

**Эльнара әниләр турында җыр башлый.**

**Эльвина:** Бигрәк матур җыр, Эльнара.

Бүлдермәдек инде.Тик җыр кошлар турында түгел бит,әниләр турында.

**Кызлар:**Әйе

**Эльнара:** Ярый инде, без җиңелдек.Шул матур җырны сезгә җырлап ишеттерәсем килде.

**Лиана:**. Әйдәгез, табышмаклар әйтешәбез.

**Радим** :Мин башлыйм

Кышын безне җылыта, ә җәен йоклап ята,ачык һәрчак авызы, нәрсә бирәсең йота. (мич.)

**Зилә**: Мич.

Хазер мин әйтәм, кызлар.

Яңа туган айдай бөгеләмэн ,әммә мин ай түгелмен. Иртән ,кичен, көндезен, Су юлында йөримен. Ул эйбер эбинең ызбасында бар.

Нәрсә ул кызлар?

**Рината**: Мин таптым. Менэ ул, көянтә.

Хәзер мин әйтәм.

Кышын безне җылыта, ә җәен йоклап ята, һәрчак ачык авызы, нәрсә бирсәң дә йота. (мич.)

**Виолета**: Ә хәзер , мин.

Авызым юк үземнең, ашатам бөтенесен. (кашык.)

(Всех кормлю с охотою ,а сама без ротая.)*(ложка.)

Әбинең ызбасында бар бу әйбер.

**Эльвина**: Тапмадыгыз мыни, кызлар.Менә бит ул-кашыклар.(кашыкларны кулына ала)

**Кызлар:**И-и-и,чынлап та кашыклар бит .

**Эльвина** : Элеке минем бабакай кашыкларны, юкә агачыннан,үзе ясаган. .Шунысы кызык,кунакка бит, элеке, үз кашыклары белән йөргәннәр

**Рината** :Ә нигә ?

**Эльвина** :Белмим,әйдәгез әбидән сорыйк.

**Әби**: Ул кадәр кашыкларны ясарага һәркайсының осталаклары да җитмәгәндәр ,мөмкинчелекләре дә булмагындыр күрәсең. Аннан соң агач кашыклар тиз кителеп,кулланышка ярамаган. Сере шунда гына дип уйлыйм,балалар.

**Эльнара**: Кызлар, кашыклар белән ашыйлар, ә тагын кайда кулланып була?

**Рината** : Музыкага кушылып уйнап була .

**Зиля**: Әйдәгез, уйнап алаыйк.

**Кашык җитмәгәннәр,поднос, калак һәм чынаяк, кыскыч һәм дә башка музыкага кушылып уйнарлык  предметларны алалар.**

**Тагир:** Ә миңа нәрсә?

**Эльвина:** Әнә, кыскычны ал .

**Таһир барып ухватны ала.Кызлар көлешәләр.**

**Эльнара:** Бу  кыскыч түгел,ухват.(кыскычны алып бирэ)

**Халык җыры “Карабай”ны уйныйлар һәм җырлыйлар.**

**Әби чыга.**

**Әби:** Рәхмәт ,балалар,үткәнебездәге  көнкүренеш әйберләрен белмәсәгез дә,телегез үткәнебездә торып калмаган ,бигерәк матур сөйлисез,җырлыйсыз.Менә шулай телебезне,үткәнебезне онытмыйк саклыйк,киләчәккә тапшырыйк.Бу безнең изге бурычыбыз.

**Алина:** **Ү**зегезгә рәхмәт, әби. Безгә бик тә күңелле булды. Сездән без бик күп кызыклы нәрсәләр турында ишеттек, күрдек , таныштык. (иптәшләренә карап) . Безгә кайтышырга вакыт.

**Әби**: Ә бәлешләп, чәйләп алмыйбызмыный? Кызым, өстәлгә чакыр дусдарыңны.

**Балалар:** Юк, юк, рәхмәт, әбекәй. Сау булыгыз.

**Әби:** Туктагыз әле.туктагыз алайса, балалар.(тәмле сондыкны ача)  Чәк-чәк белән сыйлыйм үзегезне.

Музыка.

Балалар чәк-чәктән авыз итеп, саубуллашып чыгып китәләр.